| | |
|---|---|
| Совет Старочукалинского сельского поселения Дрожжановского муниципального района Республики Татарстан | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советы |

==========================================================================

РЕШЕНИЕ КАРАР

Иске Чокалы авылы

24 сентябрь 2024 ел № 39/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»15.11.2019 ел, № 52/2 карарына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чокалы авыл җирлеге Советы карар чыгарды**:**

1. Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 15.11.2019 ел, № 52/2 карарына (19.05.2020 ел, № 56/4, 15.11.2022 ел, №21/3, 12.10.2023 ел, № 31/2 редакциясендә), **2 пунктның 4 пунктчасына** түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«РФ Салым кодексының 378.2 маддәсе 7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы күрсәтмәсе белән раслана торган исемлеккә кертелгән гомуми мәйданы 1 000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) карата -1,2%;".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чокалы авыл җирлеге Уставы нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә..

Иске Чокалы авыл
җирлеге Башлыгы: Р.Р.Низамутдинов